РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» май 2022 ел Буа шәһәре № 56-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Зур Фролово авыл җирлегенең
генераль планына үзгәрешләр кертү
проекты буенча фикер алышу буенча ачык
тыңлауларны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24, 28 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставының 16 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2007 елның 14 маендагы 5-16 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районында гавами тыңлаулар турында нигезләмә нигезендә, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып торуын һәм авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып һәм халык алдында тыңлаулар аша фикер алышуларда катнашу хокукларын үтәү максатыннан чыгып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 10 июненә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны түбәндәге адреслар буенча үткәрергә:

- Татарстан Республикасы, Буа районы, Зур Фролово авылы, Гагарин урамы, 7 нче йорт, авыл мәдәният йорты бинасы 9: 30 сәгатьтә;
- Татарстан Республикасы, Буа районы, Каенлык авылы, Совет урамы, 5 нче йорт, авыл мәдәният йорты бинасы 11: 00 сәгатьтә;
- Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Степановка авылы, Колхоз урамы, 11 йорт, 13: 00 сәгатьтә.

3. Гавами тыңлауларны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2007 елның 14 маендагы 5-16 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районында гавами тыңлаулар турындагы нигезләмә нигезендә үткәрергә

4. Фикер алышына торган мәсьәләләр буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар ТР, Буа муниципаль районы, Буа ш., Жорес ур., 110А й., 9 бүлмә (эш көннәрендә-8.00 дән 17.00 гә кадәр) адресы буенча тапшырылырга мөмкин. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты- 2022 елның 9 июненә кадәр. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү вакытында язма яки телдән дә бирелергә мөмкин.

4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына:

- гавами тыңлаулар үткәрү башлануы турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.r адресы буенча һәм «Знамя» («Байрак», «Ялав») басма газетасында, шулай ук Буа муниципаль районының рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru әлеге карарны бастырып чыгару юлы белән һәм авыл җирлегенең гавами тыңлауларда катнашучыларның әлеге мәгълүматка үтемлелеген тәэмин итә торган мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халукка җиткерергә:

1) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар, җыелышны яки җыелышларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат;

2) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм мондый проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат;

4) экспозицияне яисә проект экспозицияләрен ачу датасы, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозицияләре, мондый проектның экспозициясен үткәрү сроклары, күрсәтелгән экспозицияләрне карау мөмкин булган көн һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

5) гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы турында мәгълүмат;

- Генераль план проектын һәм аңа мәгълүмати материалларны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адрес буенча урнаштырырга;

- 2022 елның 31 маеннан 10 июненә кадәр ТР, Буа муниципаль районы, Зур Фролово авылы, Гагарин урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында гавами тыңлауларда каралырга тиешле Генераль план проекты экспозициясен ачарга һәм үткәрергә. Экспозицияне эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату оештырылырга тиеш;

- гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге:

- әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм «Знамя» («Байрак», «Ялав») басма газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://buinsk.tatarstan.ru.

- гавами тыңлауларга әзерлекне, билгеләнгән сроклар буенча гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар протоколын әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырырга һәм «Знамя» («Байрак», «Ялав») басма газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://buinsk.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2022 елның 20 маендагы 51-п номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф. Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы Р.Р. Камартдинов